РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«24» апрель 2018 ел № 153

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2016 елның 16 июнендәге «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнарында хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында нигезләмәне раслау хакында» 47 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында законнарны үтәүне тикшереп торуны көчәйтү максатларында Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 19 сентябрендәге 431 номерлы указлары нигезендә, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы Указы белән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2016 елның 16 июнендәге 47 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнарында хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турындагы нигезләмәнең 14 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

«14.4. Әлеге Нигезләмәнең 14.1, 14.2, 14.3 пунктларында каралган мотивлаштырылган бәяләмәләр үз эченә алырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 13 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацларында һәм «б» пунктчасының икенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрнамәләрдә күрсәтелгән мәгълүмат;

б) соратулар нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 13 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацларында һәм «б» пунктчасының икенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 20,21, 23.1 нигезендә яисә башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр».

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (Pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Муниципаль район
башлыгы, Совет рәисе                                        Ф.М. Дәүләтшин